ПРОЕКТ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2025 елның «__» маеннан № ____

2025 елның II кварталына торак урынының бер квадрат метр гомуми мәйданының уртача бәясен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 03 октябрендәге 888 номерлы карары нигезендә, 2025 елның I кварталына торак урыннарының бер квадрат метры бәясенең уртача күрсәткечен билгеләү буенча «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр союзы» коммерциячел булмаган партнерлыгының Эксперт-консультация советы тикшеренүләре нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак – коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасының «2020 – 2025 елларга Яңа Чишмә муниципаль районында Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру кысаларында, авыл җирендә яшәүче яшь гаиләләрнең торак шартларын федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты исәбенә яхшырту чараларын үткәрүгә социаль түләүләр күләмен хисаплап чыгару өчен 2025 елның II кварталына торакның гомуми мәйданының бер квадрат метры бәясе 49089 сум 00 тиен күләмендә дип расларга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https:/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче Е.А. Тарнавский